# Шәхси бренд буларак татар телен саклау: «Татарча. Икенче сулыш» инициативасы

**Башкаручы:**
Нурлат шәһәре
4 нче урта гомуми белем мәктәбенең
11 нче Б сыйныф укучысы
Морадыймова Алсу

**Җитәкчесе :**
туган тел һәм әдәбияты укытучысы
Мифтахова Г.Г.

# Проектның максатлары һәм бурычлары

**Төп максат:** Татар телен яшьләр арасында популярлаштыру, куллануны җиңеләйтү

**Бурычлар:**

1. Кызыклы һәм файдалы өч төп онлайн-продукт төзү
2. Продуктларны сыйныфташлар арасында тарату
3. Проект ахырында гипотезаны тикшерү өчен сораштыру үткәрү.



# Эш планым
# (Мин нәрсә ясыйм?)
# «3 Баскыч» принцибы

| Баскыч | Исеме | Максаты | Эшләр |
|---|---|---|---|
| Тарихны теркәү | "Бабайлар сүзлеге" | Югала барган сүзләр, мәкальләр җыю | Гаилә әгъзалары белән әңгәмә 15-20 сүз/мәкаль теркәү Google Tables-та таблица төзү |
| Хәзерге заман белән тоташтыру | "Һөнәрләрне-татарча" | Киңәш ителгән һөнәрләр өчен терминнарны аңлату | 3 популяр һөнәр сайлап, һәрберсе өчен 4 термин 30 секундлык видеолар ясау |
| Киләчәк өчен мирас | "Милли стикерпак" | Татар мәдәниятенә багышланган стикерлар | Идеяләр эзләү Canva-да сызу Telegram-да урнаштыру |

# Миңа нәрсә кирәк булыр?

**Ресурслар:**
- **Вакыт** : Атнага 2-3 сәгать
- **Техник ресурслар** :
  - Смартфон (төшерү һәм монтаж)
  - Компьютер/ноутбук (Canva, Google Tables)
  - Интернет

**Финанс чыгымнары** :
- **Барлыгы 0 сум**
  - Барлык программалар бушлай
  - Стикерларны урнаштыру бушлай
  - Контентны тарату бушлай




# Көтелгән нәтиҗәләр

01

- 20 сүз/мәкаль белән "Бабайлар сүзлеге"
- 3 темага 12 татарча термин белән видеороликлар
- 8-10 стикерлы Telegram-пакет

02

- Сыйныфташларның 50%-ы контентны карар
- 10-15 әгъза яңа сүзләрне өйрәнер
- Мәктәп төркемнәрендә проект турында сөйләшү
- Иң мөһиме: татар телендә иҗат итүнең җиңел, кызыклы һәм файдалы икәнлеген күрсәтү



# Гамәли әһәмият һәм проект катламнары

01

Шәхси катнашу — һәркем үз гаиләсендә татар телен саклау һәм үстерү эшендә актив катнаша, телнең киләчәге өчен җаваплы була.

02

Җәмәгать файдасы — барлык эшләнгән материаллар ирекле таратыла, телне өйрәнү һәм куллану мөмкинлекләрен киңәйтә.

03

Киләчәк өчен нигез — проект киләчәктә дәвам итәчәк, татар телен яшьләр арасында популярлаштыру һәм буыннан-буынга тапшыру өчен база тудыра.